**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КОРКАЧЫК АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Коркачык тимер юл разъезды поселогы, Гагарин ур., 7

**СОВЕТ КУРКАЧИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район,
пос.ж.д.рзд. Куркачи, ул. Гагарина, 7

Тел./факс: +7(84365) 71-2-15, e-mail: Kurk.Vsg@tatar.ru

КАРАР
29 октябрь 2019 ел

РЕШЕНИЕ
№ 136

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр Исемлеген раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы 1 бүлеге 3 пунктчасы нигезендә, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы белән эш йөртеп, Коркачык авыл җирлеге Советы,

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр Исемлеген расларга.
2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Башкаруны контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Салихзянов

Кушымта

Расланган
Биектау муниципаль районы
Коркачык авыл җирлеге Советы
карары белән
29.10.2019 № 136

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОРКАЧЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ ТАРАФЫННАН КҮРСӘТЕЛӘ ТОРГАН МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

| № т/б | Муниципаль хезмәт исеме |
|---|---|
| 1. | Адреслар бирү, үзгәртү, юкка чыгару |
| 2. | Документлар күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген аныклау |
| 3. | Нотариаль эшчәнлек башкару: васыятьне аныклау яки ышаныч кәгазен аныклау |
| 4. | Белешмә (өземтә) бирү |
| 5. | Агачларны, куакларны кисүгә, аларның ябалдашларын кисүгә яки утыртуга рөхсәт бирү |
| 6. | Капиталь төзелеш объектын планлаштырылган бетерү турында хәбәрнамә, капиталь төзелеш объекты бетерү тәмамлану турында хәбәрнамә кабул итү |